## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Михайловка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2025 ел** **№ 6**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлегендә Михайловка авылында 2025 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча уткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорная, Нижняя урамнары буенча юл - урам челтәренең автомобиль юлларын тигезләү өчен вак таш сатып алу)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 27 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 17 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 17 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл

җирлегендә Михайловка авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорная, Нижняя урамнары буенча юл - урам челтәренең автомобиль юлларын тигезләү өчен вак таш сатып алу)

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Михайловка авылы, Тау өсте урамы, 5 йорт адресы буенча,интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Чүриле авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Рамазанов